ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 344 2017 елның 31 мае

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 12 маенда кабул ителгән 319 номерлы «Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге кече һәм урта эшкуарлык субъектларын, субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен, сайлап алу тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Дәүләт программасының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» ярдәмче программасы, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 28 декабрендәге 1740 номерлы карары белән расланган «2017-2020 елларга «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм итү һәм үстерү» муниципаль программасы нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 12 маенда кабул ителгән 319 номерлы «Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге кече һәм урта эшкуарлык субъектларын, субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен, сайлап алу тәртибе турында» (алга таба – Тәртип) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Тәртипнең 1.5. пунктындагы 10 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «эшкуарлыкны яңа башлап җибәрүче субъект – кокурс гаризасы биргән мизгелгә аны теркәү вакыты бер елдан да кимрәк булган эшкуарлык субъекты;».

1.2. Тәртипнең 2.1.1. пунктындагы б) пунктчасында «алты айдан артык» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.3. Тәртипнең 4.1. пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«физик зат - шәхси эшмәкәр яки юридик зат җитәкчесе паспортының тутырылган битләре күчермәсе;».

1.4. Тәртипнең 4.1. пунктындагы 4 абзацында «турында Федераль законнарга» сүзләрен «Федераль законга» сүзләренә алмаштырырга.

1.5. Тәртипнең 4.2. пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян

итәргә: «Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2017 елның 20 гыйнварындагы  ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган, бәйгегә гариза бирелә торган айның беренче числосына булган халәттә бирелгән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча эшкуарлык субъектының үтәлмәгән йөкләмәләре булмауны раслаучы салым органы белешмәсе;».

1.6. Тәртипнең 5.11. пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Өстәмә 1 балл бизнесны үстерү өлкәсендә, шул исәптән Россия Саклык Банкы  Google компаниясе белән берлектә гамәлгә ашыра торган «Бизнес-класс» белем бирү проекты кысаларында белем алган эшкуарлык субъектларына бирелә.».

1.7. Тәртипнең 5.14 пунктында «һәм эшкуарлык субъекты теркәлгән муниципаль берәмлек» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.8. Тәртипнең 7 бүлегендәге 5 абзацында  «7.3.» санын «7.2.1.» санына алмаштырырга, Тәртипнең 8  бүлегендәге 36 абзацында «8.6.» санын «8.7.» санына алмаштырырга.

1.9. Тәртипнең 7.3. пунктындагы 1 абзацын  түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «7.3. Субсидияләр икътисадый эшчәнлек төрләренең түбәндәге төркемнәре һәм төркемчәләре буенча төп һәм (яки) өстәмә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы һәм бизнес-проектны тормышка ашыручы эшкуарлык субъектларына бирелә (техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның 2014 елның 31 гыйнварындагы 14-ст номерлы боерыгы белән кабул ителгән икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД 2) ОК 029-2014 (КДЕС Ред. 2) нигезендә):»..

1.10. Тәртипнең 7.7. пунктындагы 4 абзацын  түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә әлеге Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында вәкаләтле затның имзасы һәм эшкуарлык субъекты мөһере (юридик затлар өчен) белән расланган (Россия Федерациясе законнарында мөһер булу бурычы билгеләнгән очракларда) яисә үз кулы белән расланган (индивидуаль эшкуарлар өчен) гарантия хаты.».

1.11. Тәртипнең 8.3.1. пунктындагы 7 абзацын һәм 5 нче кушымтаның 13 пунктындагы таблицаның 1 баганасындагы 6 юлын  түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «бәйге гаризасын бирү датасына кадәр 2 (ике) ел дәвамында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И. Беляевка йөкләргә.

А.Г. Сәйфетдинов